# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче Красная Горка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 13 «30» октябрь, 2025 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче матдәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 матдәсе, Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылында 2025 елның «30» октябрендә, узарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын түбәндәге беркетмәсе нигезендә:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карау: (вак таш җәелгән юлларны ремонтлау, ком һәм вак таш түшәлгән юлны ремонтлау, юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру, юлларның асфальтланган урыннарына юл билгеләре сызу, урам юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү:(спорт мәйданчыкларын ремонтлау);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау: (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру):

« ӘЙЕ » « ЮК »

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган, җыенда катнашучылар исемлегенә 909 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 468 кеше, 51,4% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 460 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 8 граждан тавыш бирде;
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләрен - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карау: (вак таш җәелгән юлларны ремонтлау, ком һәм вак таш түшәлгән юлны ремонтлау, юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру, юлларның асфальтланган урыннарына юл билгеләре сызу, урам юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү:(спорт мәйданчыкларын ремонтлау);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау: (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гиззатуллина